**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СЕМИОЗЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
420099, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Семиозерка, ул. Верхняя, 99А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕМИОЗЕРКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
420099, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Семиозерка авылы, Верхняя ур., 99А

тел./факс 8(84365) 32-9-63, e-mail: 7ozer.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 22 октябрь 2020 ел** **№ 486**

**Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлегенең бухгалтерлар хезмәте өчен түләүне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 августындагы 655 нче номерлы «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карары нигезендә, Биектау муниципаль районының Семиозерка авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Семиозерка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 26 октябрендәге 393 нче номерлы «Баш бухгалтерлар һәм бухгалтерларның, Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендә аерым оешмалар хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге Башкарма комитетының хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләре хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карары белән расланган «Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлегенең бухгалтерлар хезмәте өчен түләүне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) оештыру һәм шартлары турында» Нигезләмәнең 3 пунктына «Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең бухгалтерларның вазыйфаи окладлары» таблицасына, (15.10.2020 № 484 Карары редакциясендә) түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш бухгалтер | 16171 |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында:

http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Семиозерка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И.Корнилов